| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабрь 2025 ел № 15

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 26.04.2021 ел № 19 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 03.10.2025 елгы 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә», Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының 26.04.2021 № 19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (27.02.2023 № 70, 18.08.2023 № 85, 29.11.2024 № 116 үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Нигезләмәнең 11 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: югары белем яки урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарында югары, төп һәм әйдәп баручы позицияләр төркемнәре өчен, шулай ук өлкән һәм кече позицияләр төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына: муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - ким дигәндә бер ел яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча ким дигәндә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча ким дигәндә бер ел эшләү.

Әйдәп баручы, өлкән һәм кече төркем вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тиң хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төр вазыйфаларында эшләү стажы да исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы Л.М.Михайлова